

# Яңа әдәби җыентык

Чаллы төбәге үзенең табигате, инфраструктурасы, язучылары белән горурлана ала. Зур төзелеш башланган чорларда, каләм тибрәтүче яшь иҗатчылар җыелып, 1963 елда "Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсен төзи. Ләйсәнлеләрнең эшчәнлегенә багышланган чираттагы яңа "Әдәби Чаллы күгендә" китабы дөнья күрде.

Әлеге басма шәһәребездә яшәп иҗат иткән, 1979-80 елларда "Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсен җитәкләгән, шагыйрь Мәхмүт Газизовның шәхси архивында сакланган "Дулкын Иле" кулъязма китабына нигезләнеп эшләнгән. Күп әзләнүләр таләп итүче җыентык, 2007 елдан "Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсенең җитәкчесе, әдәбият тарихы музее мөдире Роза Хәмидуллина тырышлыгы белән басылып чыккан.

Китап шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Мәрван улы Хәлимовның кереш сүзе белән башланып китә. Аның «Үткән гомер әрәм тоелмас» мәкаләсендә: "Иҗади берләшмәдә каләм чарлаган егет һәм кызларның байтагы бүген татар әдәбиятының иң мәртәбәле биеклекләренә күтәрелде. «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе, менә инде илле җиде ел дәвамында, Кама буе төбәгенең иҗат көчләрен үз тирәсенә туплап, алар өчен әдәби мәктәп ролен үтәп килә", дип язган сүзләренә юлыгабыз. Аннан җыентыкта ләйсәнлеләр турында 1970-1990 елларда ук үз фикерләрен җиткергән: Фикрәт Табиев, Юныс Әминов, Рөстәм Мингалимов, Фәрваз Миңнуллин, Сажидә Сөләйманова, Рәис Беляев, Хәмит Булатов, Рафаэль Мостафин, Разил Вәлиев, Вахит Имамов, Рәшит Бәшәр, Гөлзада Рзаева, Факил Сафин һәм башка егермедән артык күренекле кешеләрнең язмалары урнаштырылган. Җыентыкта, 1969-1984 елларда КПССның Чаллы шәһәре комитеты беренче секретаре булып эшләгән Рәис Беляевнең кызыклы гына язмасына тап буласың: "...Алар беренче нигез ташы салынганнан алып, бүгенге көнгә кадәр безнең иң якын ярдәмчеләребез булды, үзләренең әсәрләре һәм ялкынлы сүзләре белән эшчеләрне һәм төзүчеләрне, инженер-техник работникларны һәм җитәкчеләрне яңадан-яңа җиңүләргә рухландырып торды", – дип фикерен җиткерә. Шулай ук үз истәлекләре белән, «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең иң беренче әгъзасы Сәлимә Шәрипова да уртаклаша: "...Без, «Ләйсән» әдәби берләшмәсе әгъзалары, язучылар белән гел аралашып яшәдек. Шәһәребездә үткәрелгән төрле чараларда, авылларда үткән әдәби-музыкаль кичәләрдә язучылар белән бергә без, «Ләйсән»леләр дә, чыгыш ясадык". Язучы Вахит Имамов, 1997-2015 елларда Татарстан язучылар берлегенең Яр Чаллы оешмасы рәисенең: "Ләйсән – кешелекнең иң көтеп алынган яңгыры бит. «Ләйсән» берләшмәсенең иҗат тамчылары һәм иҗат чишмәсе дә һәрвакытта сагындыргыч, бәрәкәтле һәм шифалы булсын!" – дип язган теләкләре белән дә очрашабыз.

Җыентыкта берләшмәнең башлангыч чорында иҗат белән шөгыльләнгән, моңа кадәр шәһәребезнең әдәбият дөньясында күләгәдә кала биргән егет-кызлар (Франц Галин, Андрей Колчерин, Вәис Мөхәммәдиев, Розалин Нәгыймуллин, Рәис Риян, Мөнир Талипов, Ясир Шакиров, Хәбирә Шаһиева һ.б.) иҗаты белән дә танышырга мөмкин. Шуларга өстәп алар арасында танылган "Мәк чәчәге" җыры авторы Альберт Абдуллин да бар. Шулай ук Түбән Камада яшәүче Нурулла Гаптуллин, Никифор Тукмачев, Казан каласында гомер итүче галимебез Николай Евстафьев һ.б. барлыгы сиксән тугыз иҗат әһелен үз эченә алып, дүрт бүлекне берләштерә.




Очрашуда, беренчеләр арасында хезмәт куйган, Заһидә Нәбиуллина да истәлекләре белән уртаклашты. Ул үз чыгышында: "Табигатьнең нинди булуына да карамастан, берләшмәнең утырышына Казаннан Мәхмүт Хөсәен, Хәсән Туфан, Рәшит Гәрәй һ.б. язучыларның яшь каләм тибрәтүчеләргә киңәшләрен биреп китүләре бу батырлыкларга тиң. Танылган әдипләребезнең фикер-юлламалары һәркемне иҗат итәргә илһамландырды. Ләйсәнлеләрнең иҗат җимешләре ул елларда республика вакытлы матбугат битләрендә еш басылып килде", – дип хатирәләрен яңартты. Шушы сүзләрне дәлилләп Рафаэль Мостафин язган түбәндәге сүзләргә дә юлыгабыз: "...КАМАЗга барган саен, мин «Ләйсән» утырышында булырга тырышам... Яшь шагыйрьләр төрле авторитетлардан куркып кала торганнардан түгел, кирәк икән, күңелләрендәге барлык уйларны сибеп ташларга да күп сорамый", – дип искә ала язучы. Кичәдә ветеран журналист Нәсимә Садыйкова үзенең 18 яшендә язган шигырьләрен китапта күреп, дулкынлануын белдерде. Шулай ук котлау сүзләре белән Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Чаллы язучылар оешмасы рәисе Факил Сафин чыгыш ясады.

Чара барышында 1981-1985 елларда "Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе булып эшләгән язучы Рафис Салимҗанов үз чыгышында басмада талантлы чордашлары Рәүф Гыйззәтуллин, Габделхәй Метшин һ.б. иҗатларын күрүенә шатлануын әйтте. Шәһәребез шагыйрьләре Галиәхмәт Шаһи, Айрат Суфиянов, Рәкыйт Аллабирде үз фикер-теләкләрен җиткерде. Шулай ук чарада Түбән Кама шәһәреннән килгән Нурулла Гаптуллин, "Кама таңнары" әдәби берләшмәсенең сәркәтибе Рушания Габбасова да Чаллының әдәби мохитенең дус-тату мөнәсәбәттә, нәтиҗәле һәм уңышлы иҗат итүләрен ассызыклап үттеләр.

"Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсе үз канат астына бик күп мәдәният хезмәткәрләре, җырчылар, театр әһелләре, композиторларны сыендырып хезмәт куя. Алар арасында композиторлар Зөфәр Сәгыйтов, Хәмит Булатов та, музыка хезмәткәре Роберт Галиев, театр әһеле Булат Салахов та бар.

Кичәгә яңа бер төсмер өстәп, Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының, Татарстанның атказанган артисты, "Ләйсән" берләшмә әгъзасы Гөлфия Фәйзрахманова Туфан Миңнуллинның "Хушыгыз" пьесасыннан "Миләүшә" монологын укучыларга җиткерде.

"Әдәби Чаллы күгендә" җыентыгының өченче бүлеге бүгенге көндә "Ләйсән"гә йөргән иҗатчыларны үз эченә алган. Анда иң яшь иҗат әгъзасына 24 булса, иң олы ләйсәнле Асия Хәсәновага, көз аенда 85 яшь тулачак. Ә алар арасында төзүче, сатучы, хисапчы, укытучы, тәрбияче, эшмәкәр, табиб, хәрби, завод эшчеләре һәм башка төрле һөнәр ияләре дә бар. Ләйсәнлеләр талантлы, аларның үз автор-башкаручылары да күп. Кичә дәвамында Фәридә Сәхәбиева, Нәгыйм Шәйхи, Флүрә Талипова башкаруында җырлар яңгырады. Ә чара Рушания Гыйләҗева сүзләренә язылган "Ләйсән – моңлы бишегебез" гимны белән тәмамланды.

**Акйолдыз ЯНМУРЗИНА,**
Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе хезмәткәре.